# Күкнең җиденче катында

**Балалар һәм яшүсмерләр газетасы**

**Октябрь, 2020 ел**

## «Минем Татарстаным» бәйгесе нәтиҗәләре

Мәктәбебезнең укытучылар һәм укучылар коллективын «Минем Татарстаным» исемле Республика иҗади эшләр бәйгесендә җиңүләре белән котлыйбыз!

Бәйге Рәсәй Мәгариф министрлыгы, КФУ җитәкчелеге, филология һәм мәдәниара коммуникацияләр институты тарафыннан уздырылды.

Бәйгене оештыруда һәм катнашуда югары нәтиҗәләр күрсәткән укытучыларны: Абдуллина Д.А.(мәктәп директоры), Хәмзина С.Р., Лицова Л.А., Закамская Н.А., педагог-организатор, Кочин М.В.- кайнар тәбриклибез. Эшләрендә уңышлар телибез!

## Мәктәп яны ял лагеры

Менә инде уку елының 1 нче чирегe дә артта калды. 1 нче ноябрьдән мәктәп яны ял лагеры эшли башлады. Көннәр иртәнге мавыктыргыч зарядкадан, тантаналы линейкадан башланды. Шулай ук “Ромашка”лар бәйгесе уздырылды. Укучылар үзләренең музыкаль сәләтләрен күрсәттеләр, төрле спорт бәйгеләрендә катнаштылар.

Лагерьда төрле кызыклы чаралар уздырылачак.

# Юл йөрү кагыйдәләре



Балаларны юл йөрү кагыйдәләренә өйрәтү - заманыбызның иң актуаль мәсьәләләренең берсе.

Бу юнәлештә безнең мәктәбебез даими рәвештә эш алып бара. Бүген дә “Куркынычсызлык атналыгы“ кысаларында шөгыльләр юл йөрү кагыйдәләренә, аларны тагын бер кат искә төшереп үтүгә, белгәннәрне ныгытуга багышланды. Килгән кунакларыбыз да бар иде, алар - “Юл хәрәкәте иминлеге” бүлеге житәкчесе Әхмәтжанова И.З., ГИБДД хезмәткәрләре.



“Юл йөрү кагыйдәләре - тормыш иминлеге” чарасының максаты бик житди: балаларны юл билгеләрен аера белүне, юлда хәвефсезлек кагыйдәләрен өйрәтүне дәвам итү; юлларда күзәтүчәнлекне, игътибарлыкны, мөстәкыйль фикерләүне үстерү; урамда, җәмәгать транспортында, торак зоналарда үз-үзеңне тоту мәдәниятен тәрбияләү.



Әхмәжанова И.З. һәм ГИБДД хезмәткәрләре балаларга җәяүлеләрнең юлда йөрү үзенчәлекләрен, транспортта үз-үзеңне тоту күнекмәләрен тагын бер кат искә төшерделәр, соңыннан истәлекле бүләкләр тапшырдылар.

# «КӨЗ БҮЛӘКЛӘРЕ» КҮРГӘЗМӘСЕ

Көз - уңышка бай вакыт. Хезмәтеңнең нәтиҗәсен күреп шатланасың.

Безнең мәктәбебездә «Көз бүләкләре» күргәзмәсе узды. Укучылар бик актив катнаштылар.

Башлангыч сыйныф укучылары менә шундый матур эшләр алып килгәннәр иде.



# Эшлекле очрашу

8нче октябрь көнне мәктәбебездә  яшь актриса Сибгатуллина гаиләсе белән эшлекле очрашу узды.

Гүзәл Сибгатуллина - кино һәм театр актрисасы, җырчы. татар театры тарихында калган легендар спектакльләрнең яңа куелышларында төп рольләрне башкарган артист. Ул  1987 елның 11 маенда Татарстанның Алексеевск районы Ялкын бистәсендә туа. 2008 елда Казан мәдәният һәм сәнгать университетын тәмамлый һәм Галиәсгар Камала исемендәге Татар дәүләт Академия театрында эшли башлый. Камал театры сәхнәсендәге беренче рольләре - Туфан ага Миңнуллинның Мирхәйдәр Фәйзи мелодрамасына таянып язылган «Галиябану, сылуым-иркәм» спектаклендә Галиябану һәм "Гөргөри кияүләре"ндә – Анук.

Улы - Арслан Сибгатуллин. 1нче сыйныфта белем ала. Ул - Халыкара һәм башка дәрәҗәдәге бәйгеләр җиңүчесе.



# Хәйрия эшләре

Мәктәбебез оешканнан бирле хәйриячелек эше белән шөгыльләнә. Бу хәйриячелек Республика балалар клиник хастаханәсенең гематология бүлегендә дәваланучы балалар һәм аларның әниләренә атап җыелды. Балаларга  уку кирәк- яраклары, уенчыклар, кием-салымнар һ.б. тапшырылды.

Һәрберебез үзеннән соң якты эз калдырырга тырышсын, миһербанлылыкка урын калдырсын иде.



# Тапкырларга - табышмак



*** Акыллыга да әйттем –**
**Уйлады да белде;**
**Акылсызга да әйттем –**
**Тыңлады да көлде.**
**(Табышмак)**

*** Утыз тештән чыккан – утыз адәмгә җәелә.**
**(Мәкаль)**

*** Үлчәүләрдә үлчәнми, сатылмый.**
**(Акыл)**



*** Бер байлык бар – янмый,**
**Карак та урлый алмый,**
**Төшеп тә югалмый.**
**(Белем)**

*** Ачыдан ачырак, татлыдан татлырак,**
**Усалдан усалрак, дөрестән дөресрәк**
**Нәрсә бар дөньяда?**
**(Тел)**

*** Акчасыз керәсең, хәзинә алып чыгасың**
**(Мәктәп)**

# Татарча ребуслар







## Гәҗитне басмага әзерләделәр:

Баш мөхәррир: Габдуллаҗанова А.Ф.

8 нче сыйныф укучылары:
Соколова София, Курняева Юлия, Сафина Камилла